ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**Татарстан Республикасы Бюджет кодексына үзгәреш кертү турында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2024 елның 6 июнендә
кабул ителде

**1 статья**

Татарстан Республикасы Бюджет кодексына $9^2$ кушымтаның $7^1$ пунктына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 4 – 5; 2005, № 6 (II өлеш), № 10 (I өлеш), № 12 (IV өлеш); 2006, № 6 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2007, № 8, № 10; 2008, № 8 (III өлеш), № 10 (I өлеш); 2009, № 7 – 8 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2010, № 7 (II өлеш), № 12 (I өлеш); 2011, № 8 (I өлеш), № 11 (I өлеш), № 11 (II өлеш); 2012, № 11 (I өлеш); 2013, № 7, № 10, № 11 (I өлеш); 2014, № 5, № 12 (III өлеш); 2015, № 7 (I өлеш); 2016, № 3, № 6 (III өлеш), № 9 (II өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 1 (I өлеш), № 76 (I өлеш); 2018, № 22 (I өлеш), № 78 (I өлеш); 2019, № 2 (I өлеш), № 19 (I өлеш), № 79 (I өлеш); 2020, № 51 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 94 (I өлеш); 2021, № 20 (I өлеш), № 77 (I өлеш); 2022, № 3 (I өлеш), № 34 (I өлеш), № 49 (I өлеш), № 83 (I өлеш); 2023, № 3 (I өлеш), № 20 (I өлеш), № 56 (I өлеш), № 73 (I өлеш); 2024, № 28 (I өлеш), аны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«$7^1$. I-муниципаль берәмлегенә башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белем бирүче уку-укыту программаларын, шул исәптән җайлаштырылган төп гомуми белем бирү программаларын, гамәлгә ашыручы муниципаль гомуми белем бирү оешмаларының педагогика хезмәткәрләренә сыйныф җитәкчелеге өчен айлык акчалата түләүләрне гамәлгә ашыруга субвенциянең күләмен билгеләү түбәндәге формула буенча башкарыла:

$$S_K = (T_{кр1} \times Q_1 \times N_м + T_{кр2} \times Q_2 \times N_м) \times (1+S_{взн}/100\%),$$

монда:

$T_{кр1}$ – халык саны 100 мең кеше һәм аннан күбрәк булган торак пунктларда башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белем бирүче уку-укыту программаларын, шул исәптән җайлаштырылган төп гомуми белем бирү

программаларын, гамәлгә ашыручы муниципаль гомуми белем бирү оешмаларының педагогика хезмәткәрләренә сыйныф җитәкчелеге өчен айлык акчалата түләүләрнең Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты билгели торган күләме;

$Q_1$ – i-муниципаль берәмлегендә халык саны 100 мең кеше һәм аннан күбрәк булган торак пунктларда башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белем бирүче уку-укыту программаларын, шул исәптән җайлаштырылган төп гомуми белем бирү программаларын, гамәлгә ашыручы муниципаль гомуми белем бирү оешмаларының сыйныф җитәкчелеге өчен айлык акчалата түләү ала торган педагогика хезмәткәрләренең Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең мәгариф өлкәсендә дәүләт идарәсен гамәлгә ашыручы органы тарафыннан фаразлана торган саны;

$N_м$ – башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белем бирүче уку-укыту программаларын, шул исәптән җайлаштырылган төп гомуми белем бирү программаларын, гамәлгә ашыручы муниципаль гомуми белем бирү оешмаларының педагогика хезмәткәрләренә сыйныф җитәкчелеге өчен айлык акчалата түләүләр бирелә торган елдагы айлар саны;

$T_{кр2}$ – халык саны 100 мең кешедән азрак булган торак пунктларда башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белем бирүче уку-укыту программаларын, шул исәптән җайлаштырылган төп гомуми белем бирү программаларын, гамәлгә ашыручы муниципаль гомуми белем бирү оешмаларының педагогика хезмәткәрләренә сыйныф җитәкчелеге өчен айлык акчалата түләүләрнең Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты билгели торган күләме;

$Q_2$ – i-муниципаль берәмлегендә халык саны 100 мең кешедән азрак булган торак пунктларда башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белем бирүче уку-укыту программаларын, шул исәптән җайлаштырылган төп гомуми белем бирү программаларын, гамәлгә ашыручы муниципаль гомуми белем бирү оешмаларының сыйныф җитәкчелеге өчен айлык акчалата түләү ала торган педагогика хезмәткәрләренең Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең мәгариф өлкәсендә дәүләт идарәсен гамәлгә ашыручы органы тарафыннан фаразлана торган саны;

$S_{взн}$ – мәҗбүри пенсия иминиятенә, мәҗбүри социаль иминияткә, мәҗбүри медицина иминиятенә иминият кертемнәре тарифларының берләштерелгән күләме, процентларда.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2024 елның 1 мартыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

Татарстан Республикасы
Рәисе
Р.Н. Миңнеханов

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ РӘИСЕ АДМИНИСТРАЦИЯСЕ
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2024 ел, 08 июнь
№ 34-ТРЗ